НЫКЛЫ КҮПЕР
Татарлар Мәскәүдә уңыш серләре белән уртаклашты
> 2

СИГЕЗ ӨМЕТ
Татар теленнән имтихан тапшыручылар укытучы һәм журналист булмакчы
> 2

ИР-АТ КУЛЫ
Илдар Нигъмәтҗанов әзерләгән һәр ризык теленне йотарлык
> 4

БИЛАЛЕТДИНОВ ДӘРЕСЕ
«Ак барс» Гагарин Кубогы финалына барып җитте
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 51 (29018) | Сишәмбе | 11 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ИКӘҮ ЯРАМЫЙ!

Юл бирегез: электр самокаты килә! Көннәр җылынуга, башкала урамнарын кабат самокатчылар басып ала башлады. Әле кайчан гына аның ни икәнен дә белми идек, бүген олысы да, кечесе дә заманча «тимер ат»та элдерә әнә. Ни җәяүле, ни транспорт чарасы булмаган мондый юлчыларга бәйле һәлакәтләр саны да артканнан-арта. Шуңа күрә дә быелдан электр самокатында йөрүгә бәйле махсус кагыйдәләр гамәлгә керде.

– Электр самокатында йөрүчеләрне, гомумән дә, яратмыйм, – ди Казанда унбиш елдан артык автобус йөртүче булып эшләүче Илгизәр Гатауллин. – Чөнки алар юлда ыгы-зыгы тудыра. Көтмәгән урында зур тизлектә килеп чыгып, җәяүлеләргә генә түгел, машина йөртүчеләргә дә комачау итәләр.

Болай фикер йөртүчеләр бихисап. Билгеле булганча, узган атнада башкалада электр самокатлары прокаты сезоны ачылды. Казан мэриясеннән алынган мәгълүматларга караганда, кикшеринг, ягъни электр самокатларын арендага алу һәм калдырып китү өчен башкалада 500гә якын урын әзерләнгән. Әлеге санны бу айда ук 1600гә кадәр җиткерү дә күздә тотыла. Парковка урыннары шәһәр читендәге районнарда да булачак, ди. Казан халкы һәм шәһәр кунакларына 7,5 мең электр самокаты тәкъдим итәчәкләр. Электр самокатын иярләү өчен кесә телефонындагы махсус кушымта да җитә. Бәяләре узган елгы кебек үк. Самокатны эшкә җиккәнче 50 сум түлисең дә, алга таба бер минуты – 7 сум. Аренда урыны һәм вакытына карап, түләү үзгәрергә дә мөмкин.

Бер караганда, электр самокатының өстенлекле яклары шактый кебек. Җәяү тәпилисе яки «бөке»ләрдә утырасы юк. Бензинга киткән акча да янга кала. Моңарчы самокатчыларга, кем әйтмешли, кагыйдәләр дә язылмаган иде. Нәтиҗәсе исә күз алдында. Татарстанның дәүләт автоинспекциясе мәгълүматларына караганда, былтыр электр самокатында йөрүчеләр катнашында 17 юл һәлакәте теркәлгән. Аларда, билгеле ки, ике тәгәрмәчле «тимер ат» иярләүчеләр зыян күргән. Быелдан самокатта йөрүчеләр юлда игътибарлырак булачак дип көтелә.

– 1 марттан юлда йөрү кагыйдәләренә үзгәрешләр керде. Анда «шәхси мобильлек чарасы» атамасы барлыкка килде. Моңарчы ни җәяүле, ни транспорт чарасы булмаган самокат, монотәгәрмәч, гироскутер, сигвей ише хәрәкәт итү җайланмалары хәзер әнә шул төргә керәчәк. Моннан ары алар барысы да транспорт чарасы булып исәпләнәчәк, – ди Татарстан дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы Рөстәм Гарипов.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шәхси мобильлек чарасында хәрәкәт итүчеләрнең хокуклары, ә аннан бигрәк җаваплылыгы да бар. Мәсәлән, бер самокатта икәү йөреп булмаячак.

– Мондый җайланмаларда тизлекне сәгатенә 25 чакрымнан да арттырырга ярамый. Җәяүлеләр белән бергә хәрәкәт иткәндә самокатның авырлыгы 35 килограммнан артмаска тиеш. Шул ук вакытта, тизлекне җәяүлеләрнеккеннән арттырырга ярамый. Иң мөһиме – кеше арасыннан барганда, җәяүлеләр өстенлеккә ия, – ди Рөстәм Гарипов. – Электр самокатында йөрүчегә машина юлыннан барырга рөхсәт ителгән очракта, юлның уң як чатыннан гына хәрәкәт итәргә ярый.

«Самокатчыларга кайда йөрергә ярый?» – дигән сорауга да җавап бар. Җиде яшькә кадәрге балалар, мәсәлән, фәкать өлкәннәр карамагында гына җәяүлеләр юлында, җәяүлеләр зонасында һәм велосипед юлларында йөри ала. 7–14 яшьлекләр өчен дә кагыйдәләр шул ук. Бары тик әти-әниләрнең сагалап торуы кирәкми. Өлкәннәр исә, җәяүлеләр яки велосипед юлы булмаган яки аннан хәрәкәт итү мөмкин булмаган очракта, юлның уң як чатына төшә ала. Дөрес, бу юлда машиналар өчен тизлек сәгатенә 60 чакрымнан да артмаска һәм велосипед хәрәкәте рөхсәт ителгән булырга тиеш.

– Шәхси мобильлек чараларында йөрүчеләргә юлда йөрү кагыйдәләрен бозган өчен 800 сум күләмендә штраф каралган. Моңа өстәп, исерек хәлдә дә булса, штраф күләме 1000–1500 сум тәшкил итәчәк. Транспорт чаралары хәрәкәтенә комачаулык тудыручыларга 1000 сум штраф салачаклар, – дип кисәтте республиканың баш инспекторы.

Электр самокатында йөрергә яратучыларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та өнәп бетерми. «Артык мавыкмагыз. Самокатларның әллә ни яхшылыгын күрмим. Җәяү яки велосипедта йөрергә кирәк. Болай да аз хәрәкәтләнәбез», – диде ул киңәшмәләрнең берсендә.

Бу уңайдан, Чаллы мэры Наил Мәһдиев, гомумән дә, кырт кистереп җавап бирде. Баксаң, ул оныкларына мондый җайланмаларда йөрергә рөхсәт итми икән. «Артык оныкларым юк», – диде ул, шәһәр юлларының мондый самокатларда чыгарга әзер түгеллегенә ишарәләп.

Мөнәсәбәт бөтен җирдә дә бер үк түгел анысы. «Без электр самокатлары турында берничә елдан бирле сөйләшүләр алып бардык. Әлмәт шәһәре юкка гына республиканың велосипед башкаласы исемен йөртми. Электр самокатында шәһәрнең теләсә кайсы почмагына барып җитеп була. Тирләп пешеп тәгәрмәч әйләндерәсе дә юк», – дигән иде район башлыгы Тимур Ногуманов яңа «тимер ат»лар әле кулланышка керә башлаган чорда.

Казанда яшәүче Тимур Шакиров былтыр ук дүрт тәгәрмәчле «тимер ат»ын икелегә алмаштырган.

– Электр самокатын 7 мең сумга сатып алдым. Көн саен эшкә шәһәрнең Гадел Кутуй урамыннан Компрессорный ягына таба йөрим. Электр самокаты сәгатенә 30 чакрымга кадәр тизлек җыя. Тиешле урынга 15–20 минутта барып җитәм. Бензинга киткән акчаны гына исәпләсәң дә, бер елда 40–50 мең сум акчаны янда калдырдым инде. Электр самокатын эш өчен файдаланучылар юлда йөрү кагыйдәләрен бозмый, ә аның ярдәмендә кәеф-сафа корып йөрергә яратучыларга штраф салсалар да ярый, – ди ул.

Фирая МӨХӘММӘТШИНА, табиб-травматолог:
– Баланы самокатка бастырганчы, иң элек аны дөрес итеп егылырга өйрәтергә кирәк. Кул-аяклар сынмасын өчен кулны терсәктән, ә аякларны тездән бөгәргә киңәш ителә. Кулларны тәнгә кысып кую да соңыннан табибка мөрәҗәгать итүдән саклап калырга мөмкин. Балалар самокатны аяк белән туктатырга тырышып та төрле тән җәрәхәтләре ала. Без балаларны өч яшькә кадәр, гомумән дә, самокатка бастырмаска киңәш итәбез.

Бәйрәм күчтәнәче

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге Бөек Ватан сугышында катнашкан 248 ветеранга һәм 47 сугыш инвалидына Җиңү көне уңаеннан апрель аенда елдагыча 10 мең сум акча түләячәк. Бер тапкыр бирелә торган әлеге акчаны Татарстан ветераннары апрель ае пенсиясе белән бергә алачак.

Билгеле булганча, мондый акча Россия Президенты Владимир Путин йөкләмәсе нигезендә, 2019 елдан башлап түләнә. Җиңүнең 78 еллыгы уңаеннан түләү Татарстан Социаль фондында булган мәгълүматлар нигезендә бирелә. Ветераннарга, аларның якыннарына яки вәкилләренә нинди дә булса гариза тапшырырга һәм Россия Социаль фондына мөрәҗәгать итәргә кирәкми.

13 апрельдә әйтәчәкләр

Илназ Галәвиевнең Казандагы 175 нче гимназиягә һөҗүм итү турында эшен карап тикшерү төгәлләнде. Татарстан Югары судында фикер алышулар барышында Галәвиев соңгы сүзен әйтте.

Узган атнада судта прокуратура вәкилләре чыгыш ясады. Аларга Татарстан прокуроры Илдус Нәфыйков җитәкчелек итте. Ул суд хөкеме алдына басучыны гомерлеккә ирегеннән мәхрүм итү таләбен куйды. Ул беренче биш елны төрмәдә уздырырга тиеш.

Илназ Галәвиев судтан төрмәгә җибәрмәүне сораган. Адвокаты, янәсе, үз акылында түгел, дип, аны җинаять җаваплылыгыннан азат итүне – мәҗбүри дәвалауга җибәрүне сораган.

Хөкем ителүче соңгы сүзендә, үзен гафу итүләрен сорап, китерелгән зыянны капларга тырышачагын әйткән. Хөкем карары 13 апрельдә игълан ителәчәк.

Исегезгә төшерәбез: фаҗига 2021 елның 11 маенда булды. Илназ Галәвиев Казан гимназиясенә кереп, ут ачты. Фаҗигадә ике укытучының һәм сигезенче сыйныфта белем алган җиде укучының гомере өзелде.

Экспертиза Галәвиевне, үз акылында, дип таныган. 600дән артыграк кеше зыян күргән булып санала.

Ялларга суыта

Бу атнада Татарстанда көндезге һава температурасының +20 градуска җитүе көтелә. Ләкин атна ахырында шактый ук суытачак.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, якын араларда явым-төшемсез, җилсез коры һава саклана. Чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе – 12–13 апрельдә көндез термометрның терекөмеш баганасы +14...+20 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнлә суыта: +3...–2, көнчыгыш районнарда –6 градуска кадәр.

Синоптикларның башлангыч фаразлары буенча, җомга һәм шимбә – 14–15 апрельдә, республикага төньяктан суык һава агымы үтеп керү сәбәпле, көндез һава температурасы +5...+10 градустан артмаячак. Секундына 20 метр тизлектә көчле җил. Явым-төшем юк дәрәҗәсендә.

Борчыган мәсьәлә

Эш өләшәләр. Кем ала?

Татарстанда бер эшсезгә биш эш урыны туры килә. Республика барыннан да бигрәк төзүче, шәфкать туташы, машина йөртүчеләргә мохтаҗ. Хезмәт базарындагы вазгыять белән бу атнада якыннанрак танышып булачак. Ник дигәндә, 14–15 апрель көннәрендә Татарстанда беренче тапкыр илкүләм вакансияләр ярминкәсе узачак.

Ул эшсезләр өчен генә түгел, эш бирүчеләргә, өлкән сыйныф укучылары өчен дә файдалы булачак, дип ышандыралар. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова хәбәр итте.

Министр сүзләренә караганда, бүген республикада 6,9 мең эшсез исәпләнә. Хезмәт базарында аларга 30 мең вакансия тәкъдим итәләр. Сүз уңаеннан, күптән түгел «РИА Новости» агентлыгы эшсезлек күрсәткече буенча Россия төбәкләре рейтингын төзегән. Татарстан анда бишенче урынга чыккан. Узган ел республика халкы эш эзләүгә уртача 3,5 ай вакытын сарыф иткән.

Эльмира Зарипова сүзләренә караганда, бүген республикада мәшгульлек дәрәҗәсе 62,4 процент тәшкил итә. Россия күләмендә бу күрсәткеч – 60,1 процент.

– Бүген Татарстанда эшсезлек дәрәҗәсе шактый түбән. Әмма тынычланырга иртәрәк. Бездә бүген еш кына сорау белән тәкъдимнең тәңгәл килмәве күзәтелә. Ник дигәндә, кайбер районнарда белгече бар – эше юк. Менә дигән эш тәкъдим итәбез дип торган икенче бер җирдә исә, киресенчә, кеше таба алмыйча интегәләр, – ди министр.

Инженер, электр һәм газ белән эретеп ябыштыручы, машина йөртүче, программист, штукатурлаучы, ташчы,

табиб, шәфкать туташы белән агроном... Эльмира Зарипова Татарстанда иң кирәкле һөнәрләр дип әнә шуларны атый. Ел башыннан бирле кайбер тармакларга эшкә урнашучылар саны арткан.

– Соңгы ярты ел эчендә республиканың төзелеш тармагында тир түгүчеләр саны 10 меңгә артты. Транспорт, сак, сәүдә тармакларында да үсеш күзәтелә. Аерым алганда, сәүдә тармагында эшләүчеләр 4 мең кешегә артты. Нигездә, электрон сәүдә юнәлешендә хезмәт куючы – маркетплейсларда сатучы яки социаль челтәрләрдә эшләүче SMM-менеджер хисабына ирешелгән сан бу, – ди Эльмира Зарипова.

Министр сүзләренә караганда, соңгы арада IT тармак та җанлана бара. Ә менә су белән тәэмин итү, калдыкларны җыю һәм эшкәртү, торак базары тармакларында хезмәт куючылар саны, киресенчә, кимегән.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

vk.com

Сергей КАРНАУХОВ, сәясәт белгече:

Яшерен-батырын түгел, блогерларыбызның күпчелеге Украина махсус хезмәтләре өчен чын мәгънәсендә мишень. Алардан: «Безнең көч органнары сезнең белән ниндидер эш алып барамы?» – дип кызыксындым. Баксаң, аларның берсенә дә игътибар бирүче юк. Мондый шартларда Россиянең махсус хезмәтләре белән хокук органнарына уяурак булырга кирәк югыйсә.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – КРЕДИТ

2022 елда Россиянең 79 төбәгендә банкка кредит бурычларын кайтару авырайган. Ил күләмендә вакытында түләнмәгән әҗәтнең өлеше 4,03 процентка җиткән (узган елгы күрсәткеч – 3,85 процент).

Урын	Төбәк	Вакытында түләнмәгән кредит бурычы (2023 елның 1 мартына булган мәгълүмат), %
1	Севастополь	1,97
2	Ненец автономияле округы	2,31
3	Ямал-Ненец автономияле округы	2,40
4	Санкт-Петербург	2,61
...		
11	**Татарстан**	**3,23**
12	Мәскәү	3,27
...		
85	Ингушетия	10,16

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 10–20 апрель көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен** — гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **1051 сум 80 тиен** — гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

Реклама 16+



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЯКЫН КӨНЧЫГЫШ КЫЗГАНДА

Үткән атнада дөньякүләм вакыйгалар динамикасы көчәйде. Һәрберсе стратегик әһәмияткә ия булган һәм алдагы көннәрнең агышын билгеләячәк хәлләр бер-бер артлы мәйданга чыкты.

Игътибарга лаек берничә вакыйганы гына аерып чыгарыйк. Ярымүткәргечләр сәнгате ассоциациясе, чипләр җитештерү дөньякүләм кими, дип белдерде. Кимү барыннан да бигрәк Кытайда күзәтелә. Morgan Stanley финанс холдингы: «АКШның коммерциягә кучемсез милек базарын Бөек финанс кризисы вакытында күзәтелгән начар хәлләр көтә», – дигән сүзләр әйтте. Макронның Кытайга визиты вакытында Парижда француз фетнәсе тынмады. Фетнәчеләр дөньядагы иң эре инвестиция компанияләренең берсе булган BlackRock офисын яулап алдылар.

Планетадагы вазгыятьне якынча чамалау өчен шул өч хәбәр дә җитеп торыр, мөгаен. Нәтиҗә бер һәм кыска: бөек кризис үз адымнарын тизләтә. Без аңа зур игътибар да бирмәс идек, әмма ул якын килүчәкнең зур бәрелешләренең алсәбәбе булып тора. Агымдагы вазгыятьтә дәүләтләр глобаль сәясәт тактасында үзләренә уңайлы диспозицияләр сайлау, яңа блоклар төзү белән мәшгульләр. Үткән атнада АКШның Үзәк разведка идарәсе директоры Бернс Согуд Гарәбстанына яшерен визит белән булып китте дигән хәбәр күзгә чалынды. Якын Көнчыгышта җитди үзгәрешләр әзерләнеп ята. Бу – үзе бер зур тема, без ул хакта аерым сөйләшербез, мөгаен.

Үткән атнада Фәләстыйн җәрәхәте яңадан ачылды: Эль-Акса мәчетендә гыйбриләр яңадан кыйнаш оештырды. Зур конфликтка старт бирелде. Билгесез көчләр Ливан ягыннан гыйбри башбаштаклыгына җавап итеп, Израильгә ракета яңгыры яудырды. Рәсми рәвештә 30–35 ракета очты дип саналса да, гомуми сан йөздән артты, диләр. Израильнең мактаулы «Тимер гөмбәз» ракета һөҗүменә каршы тору системасы ракеталарны тотып бетерә алмады. Ливанның «Хизбулла» төркеме дә, рәсми Бейрут та һөҗүмгә үзләренең катнашы юклыгын белдерде. Әмма вазгыять кызды. Ракеталар Газзә секторыннан да ява башлады. Израиль бомба һөҗүмнәре башлап җибәрде.

Конфликтның күпчелеге кабат туу торган әчке сәбәпләре күп. Диннәр арасындагы каршылыклар төп урынны алып тора. Бу юлы, әлбәттә, Израильдә башланган кызу фетнә төп этәргеч булды. Нетаньяху хөкүмәте конфликтны гыйбриләрнең игътибарын читкә юнәлтү максатыннан ат йөреше урынына кулланды. Вазгыятьнең динамикасын урын аз булу сәбәпле сурәтләп тормыйбыз. БМО Генераль секретаре Антонио Гутерриш Израиль агрессиясе уңаеннан шок халәтендә булуын һәм ачуын белдерде. Мисыр арадашчылыгы ярдәмендә яклар әлегә конфликтны туктатты. Израильнең хәрби яктан өстенлеге һәм АКШ канаты астында булуы, мәселман илләренең таркаулыгы әлегә гыйбриләрне лаеклы җавапттан коткара. Әммә төрек хәрби технологияләрен устеручне Сәлҗук Байрактар зур твит ясады. Анда: «Без бүген чәчкәннәр иртәгә балаларыбыз урачак тынычлыкны билгеләр», – дигән юллар бар. Идарәче төрек партиясе депутаты Дурмаз: «Аллаһ безгә Kızılelma (Кызыл алма – тиңсез юк итүче төрек пилотсыз очкычы сафка басып килә) террорчы сионист оешмасы Израильгә һөҗүм иткән көнне күрсәтсен», – дип өстәде.

Россиядә

ДОЛЛАР СИКЕРЕШЕ

Россиянең әчке сәясәтендә үткән атнаның зур яңалыгы сумның кинәт зәгыйфьләнүе, доллар алдында тез чүгүе булды. Россиянең төп басмалары үзләренең дүшәмбе саннарында аңа мөһим урын бирде.

Эш шунда: көтелгән девальвация көтмәгәндә башланып китте. Нефтькә бәяләр күтәрелү фонында Россия акчасы ныгырга тиеш иде төсле, ләкин ул үзен киресенчә тотты. Үткән көздә 57 сумга йөргән доллар җомга сәүдәсендә 83 сумлык биеклекне яулады. Евро туксан сумнан ашып китте. Америка кәгазьләре «Доллар – Африкада да доллар» дигән әйтемнең Россиягә дә туры килүен расларга омтылдылар. Бенджамин Франклин сурәте төшкән кәгазьләр кәнфит кәгазе булудан туктады. Бу уңайдан илкүләм паника күзәтелмәде. Әммә Санкт-Петербургта валюта алыштыручы теләүчеләрнең чиратлары турында хәбәрләр ишетелде.

Озак вакытлар буе санкцияләр тәэсиренә бирешмичә торыклы калган «рубль» көчен югалтты. Халыкны: «Бу хәлләр озакканмы, масштаблы девальвация көтеләме?» – дигән сораулар борчый башлады. Бер ел элек булды бит хәлләр: доллар башта 120 сумга кадәр үсте, аннан 53кә кадәр төште. Ашыгып валюта алыштырганнарның малын тыгары гына ул пычкы.

Сумның очсызлануына объектив сәбәпләр җитәрлек, билгеле. Купме генә горур калырга тырышмыйк, нефтьгаз керемнәре кими. Бердән, санкцияләр үз эшен эшли, икенчедән, дөнья икътисадының зәгыйфьлеге чимал бәяләрен төшерә. Россия сәүдә балансының профициты да кими: экспорт кысыла, импорт арта. Дәүләт бюджетының дефициты зур. Бюджет дефицитын девальвация белән каплау – Финанс министрлыгы яраткан алым. «Альфа-банк» белгечләре бюджет «тишеге»н томалау өчен долларны 115 сумга кадәр җиткерергә киракләген исәпләп чыгарды әнә. Девальвацияне кискен рәвештә үл дәрәҗәгә үк җиткермәсләр, мөгаен. Апрель ахырларына сум, бәлки, бераз ныгып та алыр. Валюта алыштырырга теләүчеләргә менә шул ныгу чорын көтәргә кирәктер. Озак вакытлы перспективада сум очсызланыр. Бу – күпчелек белгечләр фикере. Сумның көчсезләнүендә капиталның чит илгә качуы да мөһим роль уйный. 2022 елда капитал качу рекордны. Быел да әле акча тыярга тыярга җыенучы күренми.

Доллар бөтен дөньяда кыйммәтләнә, анысын да исәпкә алырга кирәк. ФРСның төп ставканы күтәрүе этәрә моңа. Девальвация импортны кыйммәтләндерер. Бюджет өчен файдалы булса да, икътисад өчен зур зыяны бар аның. Шуңа күрә үзәк хакимиятләр аны контрольдә тотарга тырышыр дип уйлыйк. Тота алсалар инде.

ТАТАРЛАР УҢЫШЫ

Гадәттәгечә, татарлар Мәскәүдә уңыш серләре белән уртаклаша. Россия башкаласында сигезенче мәртәбә «Мәскәү – Татарстан күпере» форумы узды. Ул, традиция буенча, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, эштә, сәясәттә, сәнгатьтә һәм бүтән тармакларда танылган татарлар катнашында узды. Һәрберсе «уңыш сере» белән уртаклашты, аталарча үгет-нәсыйхәт бирде.

Эшкә бирсәң чын күңел...

Дәүләт Думасы депутаты Олег Морозов, уңышка ирешү өчен, башкарган эшеңне яратырга кирәк, ди.

– Эшкә булган мәхәббәт – уңыш нигезе. Эшкә барасы килмичә барсагыз, сезне уңышсызлык көтәчәк, – диде ул үз чыгышында. – Хәзерге тормышта көндәшлек бик көчле. Көндәшлеккә каршы торырга, дәлилләр китерергә өйрәнегез.

Депутат еш кына үзеннән: «Республикам, Татарстандагы дусларым, остазларым, ата-бабам җире булмаса, уңышка ирешә алыр идемме?» – дип сорый икән. Җавабын да белә.

– Юк, уңышка ирешмәс идем. Мин профессиязез кеше бит. Минем дипломда да «фәнни коммунизм укытучысы» дип язылган. Шулай булгач, ничек мин, һөнәрем булмаган килеш, сезнең каршыда уңыш турында сөйләп торам? Җавап шул: безне Казан университетында бик яхшы укыттылар. Белем алырга, китап белән эшләргә өйрәттеләр.

«Миндә ага татар каны»

Форумга рэпер, продюсер Тимур Юнысов та чакырулы иде. Аны күбрәк Тимати булярак беләләр. Баксаң, аның да тамырлары татарларга бәйле икән.

– Татарлар – кызу канлы, үҗәт. Этидән күчкән сыйфатлар миңа күп нәрсәдә булыша. Кайбер урыннарда комачау да итә, чөнки кирелек бар. Әтием гарәп һәм татар телен белә. Бабам – язучы. Мин Казанга, Татарстанга килергә һәрвакыт шат. Чакырыгыз! – дип чыгыш ясады ул.

Пар канат – таяныч

Актер Камил Ларин исә яшьләрне ата-анасын онытмаска, туганлык җепләрен сакларга өндәде.

– Әти-әнисен оныткан, алар белән аралашмаган кешеләр... Алар инде яртылаш юк! Минә әнием көн саен шалтырата. Алар безгә гомер биргән. Кеше булсын өчен, тәләсә кайсы тармакта уңышка ирешсен өчен бирелгән ул гомер, – диде ул. – Тагын бер мөһим нәрсә – дуслар. Аларны сайлый белергә кирәк. Дустың татар булса, тагын да шәп!

tatarstan.ru

«Мин уңышлы өйләндем!»

Гадәттәгечә, форумны йомгаклап, республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов сүз алды. Ул үз фикерләрен генә җиткереп калмады, форумга килүчеләрнең сорауларына да җавап бирде. Татарстан яшәү һәм эшләү өчен кызыксындырырлык җиреме? Рәис өйләнүен уңышка саныймы? Ислам дөньясына йөз тотуыбыз ни өчен кирәк? Форумда катнашучылар шул сорауларга да җавап ишетте. Сүз уңаеннан, Рәискә дип 300ләп сорау килеп ирешкән булган икән.

– Кем кайда укырга тели, кеше моны үзе сайларга тиеш дип уйлыйм. Мәскәүдәме, Казандамы, Петербургтамы, Әлмәттәме... Яшьләр башка урыннарга күчәргә, укырга тиеш, билгеле, моннан башка үсеш юк. Мәсьәләнең башка ягы бар: сез кире кайтырга ни дәрәҗәдә әзер?. Бу безнең өчен дә сорау, чөнки безнең максат – лаеклы тормыш сыйфатын булдыру. Мәскәүдән яхшырак яшәү, әлбәттә, мөмкин түгел. Тик без моңа якынаерга тиеш. Сүз уңаеннан, узган елгы халык санын алу нәтиҗәләре Татарстанның башкалар өчен дә кызыклы булуын күрсәтә. Күпкенә төбәкләрдә халык саны кимегәндә, без 4 млн кешегә җиттек, – диде Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында. – Тагын 15 елдан, ә, бәлки, иртәрәк тә, бөтен хакимият яшьләр кулына күчәр. Без аларга нигез калдырырга тиеш.

Очрашуның өстенлеге җитдилектән азат булуындадыр. Рәис Рөстәм Миңнеханов шаяртуларга да саран булмады. Аннан: «Эшегездә һәм тормышыгызда нинди киңәш уңыш китерде?» – дип сорадылар. Ул исә, уенын-чынын кушып:

– Мин уңышлы өйләндем! Бу бик мөһим. Бик тә мөһим! – диде. Әлбәттә, аның бу җавабы алкышларга лаек иде.

Рәис республиканың мөселман дәүләтләре белән хезмәттәшлек итү өстенлекләре турында да сөйләде.

– Татарстанда халыкның күпчелеге ислам динен тота һәм безнең бу факторны өстенлегебез итәргә булдык. Шулай итеп без ислам дөньясы белән эшли башладык. Бу хезмәттәшлектә мөһим юнәлешләрнең берсе – ислам банкингы. Без бу сорауны берничә тапкыр күтәрдек, ләкин ул игътибарсыз калды. Әммә хәзер дөнья үзгәрде. Тагын бер мөһим юнәлеш – хәләл. Хәләл – ул әле ризык кына түгел, туризм да, мәгариф дә, медицина да. Ислам илләре тәҗрибә уртаклашырга әзер, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Казан Кремлендә «Тимур Акулов – аны Татарстанның тышкы эшләр министры дип атыйлар иде» дип исемләнгән күргәзмә ачылды.

Ул Россиянең һәм Татарстанның танылган сәяси һәм дәүләт эшлеклесе, дипломат, Татарстан тышкы сәясәт идарә тармагына нигез салучы Тимур Акуловка багышлана. 25 апрельдә аның тууына 70 ел була.

– 1990 нчы еллар башында Татарстан мөстәкыйль үсеш юлына баскач, республика белән идарә итүнең яңа системасы кирәк иде. Шуңа күрә тәүге тапкыр президент институты барлыкка килде. Бу институтка яңа кадрлар булдыру таләп итте. Тимур Юрьевич – шул заманның лаеклы җитәкчеләреннән берсе. Ул Татарстан белән чит илләр арасында мөнәсәбәтләрне үстерүдә хәлиткеч роль уйнады. Шул елларда республиканың чит илләрдә ачылган вәкилләкләре бүген дә уңышлы эшли», – дип искә алды күргәзмә ачылышында Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев.

Эш өләшәләр. Кем ала?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

14–15 апрель көннәрендә Татарстанда беренче тапкыр илкүләм вакансияләр ярминкәсе узачак. Эш тәкъдим итүдән тыш, анда халыкны дөрес итеп резюме төзергә дә өйрәтәчәкләр. Өлкән сыйныф укучыларына исә һөнәр сайларга ярдәм итмәкчеләр.

– «Россиядә эш. Мөмкинлекләр чоры» дип исемләнгән әлеге Россиякүләм хезмәт ярминкәсе 26 мәйданчыкта оештырыла. Ул иртәнге сәгать уннан көндезге бергә кадәр узачак. Казанда яшәүчеләрне Казан дәүләт федераль университетының икенче уку корпусында көтәләр. Анда 300ләп оешма эш урыннары тәкъдим итәчәк, моннан тыш мастер-класслар, һөнәри остаханәләр, яшьләргә һөнәр сайларга ярдәм итүне күздә тоткан чаралар да узачак. Ярминкәгә килүчеләр дөрес итеп резюме төзергә, эш бирүчеләргә дөрес итеп сорау бирергә өйрәнә алачак. Эш бирүчеләргә дә үз оешмалары, эшчәнлекләре турында тәфсилләп сөйләргә мөмкинлек тудырылачак, – ди министр.

Сүз уңаеннан, булган һөнәрен алыштырырга теләүчеләр хәзер яңасын бушлай укып үзләштерә ала. «Демография» илкүләм проекты кысасында халыкка шундый мөмкинлек тудырылган. Билгеле булганча, моңа кадәр әлеге программа нигезендә пенсионерлар гына бушлай укый ала иде. Хәзер бу мөмкинлектән декрет ялындагы яки мәктәп яшенә җитмәгән бала тәрбияләүче әниләр, 35 яшькә кадәрге яшьләр, мәшгульлек үзәкләрендә исәптә торган эшсезләр дә файдалана ала.

– Узган ел әлеге программа буенча 9 мең кеше укып чыкты. Шуларның 92 проценты яңа үзләштергән һөнәре буенча эшкә урнашты. Эшкә урнашмаучыларның да сәбәпләре бар. Кемдер авырып киткән, кемдер башка шәһәргә күченгән, – ди Эльмира Зарипова.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе генераль директоры **Хәйруллин** Рөстәм Наил улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Химия сәнгате өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Түбән Кама йөк машиналары шиннары заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең протектор агрегаты машинисты **Кәбиров** Илфат Гәбтелфарт улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Дусым» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бригадиры **Сабиров** Фарит Рафыйк улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татарстан Республикасында җирләрне сугару һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Хисмәтуллин** Марс Мансур улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Фәнни-педагогик эшчәнлегендәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты кафедрасы профессоры **Ершов** Андрей Николаевич Россия Федерациясе Президентының **Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

КАДЕРЛЕ БӨРТЕКЛӘР

БЫЕЛ 11 НЧЕ СЫЙНЫФНЫ ТӘМАМЛАУЧЫ СИГЕЗ УКУЧЫ ТАТАР ТЕЛЕННӘН БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ИМТИХАНЫН ТАПШЫРАЧАК

Туган тел

Алар Әгерҗе, Әлмәт, Балтач, Нурлат, Казанның Авиатөзелеш һәм Совет районнары мәктәпләрендә белем ала. Узган ел татарча сынауга нибары бер – Балтач районының Норма мәктәбе укучысы Әдилә Шәйхетдинова гына кергән иде. БРИны сайлаучыларның татар теле турында фикерләрен сораштык.

– Былтыр бераү булса, быел сигез укучы татар теленнән сынауга язылган. Үсеш бар. Ничек кенә булмасын, туган телләр – татар, мари, мордва, чуаш һәм башка телләргә республика тарафыннан игътибар һәрвакыт булды һәм алга таба да җавап итәчәк. Бу безне сөендерә, – диде Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин Хөкүмәт йортында узган брифингта.

Татар теле имтиханын сайлаучы укучылар арасында төрлесе бар. Кемдер туган тел укытучысы булырга җыена, кемдер журналист булмакчы.

Зилия Юнысова – Балтач районының Куныр мәктәбе укучысы. Кечкенәдән төрле бәйгеләрдә катнашып үскән туташ белемен КФУның татар теле бүлегендә дәвам иттерергә җыена.

– Укытучы булу куркытмый. Бу – минем күптәнге хыял. Телен белмәгән балаларны татарча сөйләштерәсем килә. Ул бит аларның туган теле. Болай булса, авылның килачәгенә куркыныч яный. Дәреслекләрдән гаеп эзләргә кирәкми. Аңламаган бер генә кагыйдә дә юк. Укытучы кызыксындыра белсә, берниндй проблема да юк, – ди Зилия.

Нурлат районының Кулбай Мораса мәктәбендә татар телен сайлаган өч укучы да язмышын журналистика белән бәйләмәкче. Алар – Әлфинә Хисамова, Руфинә Гыйльметдинова, Рузинә Сабирова.

Әлфинә Хисамова – Кычытканлы авылы кызы. Сынауны ул татар теленең абруен күтәрү өчен сайлаган. Бөтен нәрсә дә бигге белән үлчәнми, ватанпәрвәрлек дигән хис тә бар.

Сан

9 нчы сыйныф укучылары арасында **2501** бала татар теленнән имтихан тапшырачак. Узган ел белән чагыштырганда, бу сан ике мәртәбә артыграк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Кечкенәдән туган телемне яраттым. Район газетасында язмаларым басылып тора. Китаплар укыйм. Шуңа күрә татар теле сынавын сайладым. Без – өч кызны да журналист булырга укытучыбыз кызыксындырды, – ди Әлфинә.

Рөмзия Галиуллина Кулбай Мораса мәктәбендә 33 ел укыта икән инде.

– Татар телен атнага – 2, әдәбиятны 1 дәрес укытабыз. Югары сыйныфларда әдәбият укытылмый, әдәби мирас кына керә. Билгеле, бу сәгатьләр генә җитми. Дәрестән соң да шөгыльләнәбез, – ди Рөмзия Галиуллина.

Укытучыны башка борчыган мәсьәлә дә бар. Әйтик, чеп-чи татар авылларында әти-әниләрнең сабыйлары белән русча аралашуы.

– Балалар бакчасыннан ук татарча сөйләшергә кирәк. Сөйләшми бит алар. Үзебез дә бу хәлгә аптырыйбыз. Бакчада мохит – татарча. Өйдә – русча. Телефон да боза балаларны. Әнисе русча сөйләгәч, бала да шуны кабатлый. Укучыларга да: «Сез бит – татар балалары, туган телдә сөйләшегез», – дип кисәтү ясыйм. Бу проблеманы хәл итү өчен, район мәгариф бүлеге программа керткә. Һәр татар теле укытучысы район балалар бакчасына барып, татар теле дәресләре үткәрә, – ди Рәмзия Галиуллина.

Әгерҗе районындагы Исәнбай мәктәбе укучысы Ралинә Хәбирова да әлеге сынауны сайлаган. Аның да теләге – журналист булу. Әлеге бүлеккә укырга керү өчен татар теленнән имтихан бирергә кирәк.

– Татар теле белән кечкенә сыйныфлардан ук кызыксынам. Төрле олимпиадаларда катнаштым, җиңүләр яуладым, – ди ул. – Телне кулланучы дәүләтнең дә роле зур, әмма күп нәрсә гаиләдән килә дип саныйм. Өйдә әти-әниләр балалар белән татарча сөйләшсен иде. Сөйләшеп кенә калмасын, бергә татарча әсәрләр укысыннар, күренекле шәхесләр белән танышсыннар. Кызганыч, интернет күреп, авылда да балалар русча сөйләшергә тырыша шул хәзер. Шәһәр урамнарында, кибетләрдә йөргәндә шуңа игътибар итәм. Татарча язулар йә юк, йә булса да хаталы. Моны хәл итү өчен һаман оештырылсын иде, – ди Ралинә Хәбирова.

Укытучысы Гөлназ Хуҗинаны да республикада укучыларның татар теле сынавын аз сайлавы борчый. Аның фикеренчә, тел кулланылыш керсен өчен, ихтыяҗ кирәк. «Укучы алга таба тормышы турында уйлый да инде ул. Телнең рөлен арттырырга кирәк. Бала кечкенәдә туган телгә мәхәббәт булганда, алар икенче төрле уйлый. Без шуны уятырга тырышабыз. Мәктәп, гаилә, дәүләтнең бергә эшләве кирәк. Аккош, чуртан, кысла кебек өч якка тартканда, нәтиҗә булмый, – ди ул.

Сәрия МИФТАХОВА

«Татар-информ» / Рәмил Гали

Дүртенче туй

Шагыйрь һәм аның илһамчысы. Татарстанның халык шагыйре Ренат Харисның тормыш иптәше Лилия белән бергә гомер итә башлауларына – 60 ел! Юбилярлар «Казан» гаилә үзәгендә бриллиант туйларын билгеләп үтте.

– Бүген мин хатыныма дүртенче тапкыр өйләнәм. Беренче тапкыр моннан нәкъ 60 ел элек студент чагында, аннан соң көмеш, алтын туйда өйләндем. Хәзер менә бриллиант туебызны каршылыйбыз. Тагын берәр туйга барып җитәргә исәбебез бар, – дип сөйләде Ренат Харис. – 1963 елның 7 апрелендә хатынымны 15 сумга сатып алган идем. Тора-бара аның бәясе арта гына барды. Аның кыйммәтлеге – минем өчен, минем саулыгым балаларыма, оныкларыма, хәтта ак кәгазьгә дә кирәк. Ак кәгазьгә бер генә хәреф, бер сүз төшсә дә, ул кыйммәтлегә әверелә. Минем язган әйберләрем кыйммәтлемедер – аны мин бәяләмим. Әмма аларның һәрберсенә Лилиянең йөрәк җылысы салынган. Хәзерге көнгә килеп җитүем белән гаҗәеп бәхетлемен. Безнең яхшы гаиләнең нигезе – хатыным. «Син безгә кирәк» дип эшләтә дә эшләтә ул мине. Бәрәкәт туена кадәр дә эшләргә риза. 60 ел элек Лилиягә ничек ышанган булсам, бүген дә шулай ышанам.

Лилия белән Ренат Харисовлар Казан дәүләт педагогия институтында укыганда тулай торак буфетында танышкан. Булачак шагыйрь чиратсыз гына кереп, кефир алмакчы булган. Шунда күзлекле, кечкенә генә бер кыз егетне куып җибәргән. Эчтән генә бик ачуланган Ренат буфеттан кефирсыз чыгып киткән. Берникадәр вакыттан соң тулай торакта кичке «танцы» вакытында Ренат Лилияне күреп алып, салмак биюгә чакырган.

– Шул вакыттан бирле, бербөтен булып, матур гомер кичерәбез. Лилиямә бишенче тапкыр да өйләнергә риза, – ди халык шагыйре, Россиянең дәүләт премиясе иясе.

Харисовлар фикеренчә, озак еллар иңне иңгә куеп яшәүнең сере – сабырлыкта һәм мәхәббәтнең чын, ихлас булуында.

– Бер-береңә, туганнарыңа һәм дусларыңа хөрмәт, вакытында юл куя белү. Ныклы гаиләнең нигезендә шул ята, – дип өстәде Лилия ханым.

Харисовларны котларга балалары, онык һәм оныкчыклары, шәһәр җитәкчелеге килгән иде. Татарстан Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина юбилярларга Рәхмәт хаты тапшырды.

– Сез – безнең өчен үрнәк гаилә. Сез – гаилә ныклыгын, бердәмлеген саклап, 60 ел бергә мәхәббәт һәм аңлашуда, хөрмәт һәм соклану уятып яши торган матур парларның берсе. Шулкадәр кунакчыл, ихлас күңел белән яши торган гаилә. Лилия ханым талантлы егетне үзенә гашыйк иткән дә, гомер буе аны яратып, саклап, рухландырып яши. Беренче мәхәббәтләренә тугры калып, матур, бәрәкәтле гомер юлын узып, шушы тантаналы мизгелгә барып җитү – үзе зур бәхет, – дип котлады Гөлшат Нигъмәтуллина.

Матур парны котларга Казан Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова да килгән иде.

– Шагыйрь һәм аның илһамчысы. Сезгә карап сокланмыйча мөмкин түгел. Мәхәббәт яшәртә, диләр, сез бүген нәкъ кияү белән кәләш шикелле. Сезнең гаилә гомер буе кеше күз алдында булды. Бу – зур җаваплылык. Сез – үзегезнең балаларыгыз, оныкларыгыз өчен генә түгел, бөтенебез өчен дә үрнәк, – дип теләкләрен җиткерде ул.

Лилия белән Ренат Харисовлар ике бала үстергән. Хәзер 3 оныклары, 4 онықчыклары бар.

Ләйсән САФИНА

Ватан хакына

ҖӘМИЛ ЯНГУЧИН: «БЕЗНЕҢ ЕГЕТЛӘР НЫК ҮЗГӘРДЕ»

Сабада яшәүче Җәмил Янгучинны «Бабай» дип йөртәләр. Ике улын махсус хәрби операциягә озаткан тынгысыз ата үзенекеләрнең дә, башкаларның да күңелен күрергә тырыша.

– Кадерле улларың шунда булсын да, ничек монда тынычланып ятарга кирәк? Ике улым, апамның малае да анда, – дип сөйли Җәмил абый. – Радик белән Рамилнең яшь аралары ике генә ел. Бергә үстеләр, армиягә дә бергә киттеләр. Өлешчә мобилизация башлангач, икесенә дә повестка килде. Ул вакытта олы улым эш сәфәре белән Краснодарда иде. Икесен дә чакырганнарын белгәч, шул көнне үк самолет белән кайтып җитте. «Энем китә икән, мин дә барам», – диде. Икенче көнне китеп тә бардылар. Без бит малайларны Ватан өчен дип үстерәбез. Моны һәркем белергә тиеш. Малай тапкансың икән, ул – солдат.

Җәмил абый егетләр янына 7 тапкыр барган инде. Аларга кирәк-яраклар илткән. Ике тапкыр кунып калырга туры килгән. Блиндажда йоклап кайттым, ди. Андагы егетләрнең хәлен аңлый ул.

– Андагы хәлләрне үз күзең белән күрү кирәк. Телевизор, интернет, кеше сүзе аша гына ишетелгән хәбәрләрне таратып утырганчы, бер барып карау җитә. Яки барган кеше белән сөйләшергә кирәк. Узган елның декабрь аенда анда пычрак иде. Егетләр җәяү дә йөри алмый, аяклары сазга бата. Шунда ничек тә монда «УАЗ» машинасы алып килергә кирәк дигән уй килде. Эшләдем мин аны. Кайтып, хәрби комиссариатта әйттем, ул район башлыгына җиткергән. Тиз арада берне түгел, ике машина юнәттек. Шуларны үзем илтеп бирдем, – ди Җәмил абый. – Билем авыртса да, юл өчен борчылмадым. Күңелемне яхшы уй белән тутырдым. Барам, илтәм, тапшырам, дидем. Шөкер, Аллаһы Тәгалә ярдәм итте. Бу юлы Илгизәр дустым белән сәфәр чыктык. Бер-беребезне алыштырып, бер тәүлек дигәндә, егетләр янына барып җиттек.

Егетләргә әллә ни күп әйбер дә кирәкми икән хәзер. Ризыклары да бар, киемнәр дә җитә. Җәмил абый артып калганны, Татарстан күчтәнәче итеп, мохтаҗ картларга өләшә икән.

Җәмил абыйның килеп йөргәнен тегендәге егетләрнең күбесе әти-әниләренә әйткән. Менә шуннан соң Сабага Балык Бистәсе, Балтач районында яшәүче әти-әниләр улларына дип исемләнгән посылка китерә башлаган.

– Алар мине көтеп тора. Ничекләр бармыйм ди инде?! Әти-әниләреннән алып килгән посылканы биргәч, кош тоталармыни! Күзләре яна, авызлары ерыла, бар дөньялары онытыла. Менә шул мизгелне күрү өчен дә анда барам инде. Ә ул рәхмәт сүзләрен ишетсәгез! Күңел эри дә китә. Егетләр дә элеккеге төсле түгел инде. Алар чын ир-атка әверелде. Ни өчен киткәннәрен аңладылар.

Җәмил абый үз уллары турында әнә шулай ди. Ул аларны кечкенәдән көчле рухлы итеп үстергән. Берсе кайда, икенчесе шунда. Утка да, суга да бергә керәләр. Тик менә әниләре генә газиз балаларын сугышка җибәргәч, инсульт кичергән. Сәламәтлеге какшаган. Гел борчыла икән. Кан басымы да күтәрелеп тора. Дарулар эчеп кенә яши икән.

– Икенче улым туып, 20 ел узгач, Аллаһы Тәгалә безгә кыз бала бирде. Әмма 2 яшендә авырып китте ул. Табиблар башында шеш тапты. Артык өметләндермәсәләр дә, шөкер, яши балабыз. 14 яшен тутырды. Безнең юанычыбыз ул, – ди Җәмил абый. – Тормыш дәвам итә. Монда тыныч, ризык җитә, рәхәттә яшибез. Минем күңел гел тегендә инде. Әлегә улларым ике атнага ялга кайтты. Тиздән китәләр инде. Алар артыннан без дә юлга кузгалырбыз. Кирәк-яракларын илтербез.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Язучы сүзе

Таныш түгел әни

Җомга саен ул телефоннан шалтырата. Шалтырата да исәнлек-саулык сораша. «Килен ни хәлләрдә, балалар исән-иминме?» – ди. Шуннан мине шелтәләп ала:

– Бу атнада да кайтмыйсызмы? Шул бетми торган эшегез булды инде. Хет шалтыратып хәл белешер идегез.

Мин җавап бирмим. Ни дип әйтергә дә белмим. Ә ул дәвам итә:

– Газинурның да кайтканы юк. Оныкларны күрмәгәнгә биш былтыр булып килә. Эш дигән булып чабасыз да чабасыз. Мине уйлап та бирмисез. Үзегез өлкәнәйгәч, аңларсыз әле менә. Әни кеше көтә ул. Олыгайган балалары өчен дә өзгәләнә.

Мин тагын аптырабрак калам. Газинурны минем күргәнем юк. Хәлләрен белеп торам. Ул Казанда яши. Ике кызы бар. Берсе быел мәктәпне тәмамларга тиеш, икенчесе – студент. Кайсы вузда икәнен генә әйтә алмыйм.

– Газинур хет ике атнага бер булса да шалтыратып хәл белешеп тора әле, ә син бөтенләй оныттың, – дип дәвам итә ул. – Үзем эндәшмәсәм, колагыңа да элмисең. Кайчагында телефоныңны да алырга иренәсең. Әллә вакытың булмый, әллә кәефең. Килен белән әйбәт торасызмы соң?

– Әйбәт, Аллага шөкер, – дим.

– Анысы ярый инде, – аның тавышына елмаю кунгандай була. – Әйбәт торыгыз. Эшләрегез гел уңышлы булсын. Дөньясы да әллә нишләбрәк китте бит. Ул әйберләрнең кыйбатлыгы хәзер. Шәһәрдә дә шулай микән инде, безнең авыл кибетендә бигрәк кыйммәт. Миллионерлар авылы диярсең. Шулай булгач, сезне дә гаепләп булмый инде, гаиләне яшәтергә, балаларны аякка бастырырга кирәк. Мәшәкатьле, тынгысыз дәвер бит. Исән-сау гына яшәгез инде.

– Рәхмәт! – дим мин чын күңелдән. – Үзегез дә исән-сау булыгыз.

Сөйләшүнең болай гына тәмамланмасын мин белеп торам. Беренче кат кына түгел. Атна саен диярлек шулай шалтырата ул. Озак кына сөйләшеп алабыз. Беренчесендә: «Сез ялгыш шалтыратасыз, апа. Яңадан җыеп карагыз әле», – диюемә дә карамыйча, үзенекен сөйли башлады. Олы кешеләрдә сабыйларга хас бер эчкерсезлек, ихласлык бар бит ул. Бу да үзенең сөйләвенә, минем тыңлавыма тулы ышаныч белән сөйли. Якын күреп аралаша. Шулай булгач, тыңламыйча кала алмыйсың бит инде. Ара-тирә сүз кыстырып та аласың. Шул рәвешле без атна саен сөйләшә торган булып киттек.

– Сәламәтлегем начарланыбрак тора әле. Даруларның да ярдәме тими, – дип моңсулана. – Ат бәясенә саталар, бет кадәр дә файдасы юк. Элек бер дә алай булмый торган иде. Ярты таблетка аспирин да терелтә торган иде. Хәзер әллә алдап кына саталар ул. Бүген дә төн буена йоклый алмадым. Аяк-куллар сызлап чыкты. Сөйләсәң, сүз инде ул, сөйләмәсәң, эт тә белми. Ярый, балам, үзегез сау-сәламәт булыгыз инде. Сакланыбрак йөрегез. Син бигрәк үзеңне карый белмисең. Яшьтән үк шулай булдың. Үзең аңламасаң, киленгә әйт, яланбаш йөртмәсен сине, җылы оекбашыңны кидерми урамга чыгармасын. Бер-берегезне саклап яшәгез. Яшьлектә кызурак буласың да, олыгайгач, искә төшә ул. Адәм баласының бергә гомер иткән үз парыннан да кадерлерәк кешесе булмый. Юкка гына Ходай парлы итеп яралтмаган бит инде. Әйбәт яшәгез балам, бер-берегезнең кадерен белеп яшәгез.

Мин шушындыйрак сүзләрен һәр сөйләшү саен ишетәм. Ишеткән саен нәрсәдер аңлаган шикелле булам. Шуңа ихлас күңелдән үз әниемнең сүзләрен тыңлаган кебек тыңлыйм. Ул мине үзенең улы дип уйлый бугай. Ә мин аны гомергә бер тапкыр да күргәнем юк. Кайсы яктан булуын да, кем икәнен дә белмим. Шулай да тыңлыйм. Сөйләшүне өзсәм, өметен өзәрмен кебек тоела.

Кайсыгызның әнисе ул? Кайтып килегез әле әниегез янына. Кайта алмасагыз, үзегез шалтыратыгыз әле. Сөендерегез бер. Күңеле күтәрелеп, адымнары җиңеләеп китсен. Ул сезне картайган көнендә минем белән сөйләшеп ятар өчен үстермәгәндер бит инде.

Марат КӘБИРОВ

КҮКТӘ НИЛӘР БУЛМАС?

Җәһәт әңгәмә

Һава торышы турында «күктән хәбәр бирүләренә» без күптән күнектек инде. Оборона эшләрендә дә шундый хәлләр икәнен чамалыйбыз. «Хәзер инде космостан энәне дә, дөяне дә күреп була», – ди Рәмис ХИСАМОВ бу җәһәттән. Белеп сөйли, чөнки ул күп еллар Казандагы Аэрокосмик приборлар төзү институтында ясалма иярченнәр өчен нәкъ менә шундый приборлар эшләгән.

Хисамов Рәмис Шәрәф улы Апас районы Чүрибураш авылында туа. Казан дәүләт университетының физика факультетында «Радиофизика һәм электроника» белгечлеге буенча укый. 1977 елдан Казан шәһәрендә Дәүләт гамәли оптика институтында инженер, фәнни хезмәткәр, фәнни-техник комплекс мөдире урынбасары булып эшли. Ленинградта дәүләт оптика институты аспирантурасын тәмамлап, техник фәннәр кандидаты фәнни дәрәҗәсенә диссертация яклый. 1991 елда яңа оештырылган Аэрокосмик приборлар институтының фән эшләре буенча директорның беренче урынбасары итеп билгеләнә. СССР Хәрби сәнәгать министрлыгының Мактау кәгазе белән бүләкләнә. «Татарстан Республикасының атказанган фән һәм техник эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.
Рәмис Шәрәф улы – 70тән артык фәнни хезмәт һәм берничә патент авторы. Бик күп студентларның курс һәм диплом проекты эшләрен яклауны оештыра, фәннәр кандидаты дәрәҗәсен эзләүче берничә хезмәткәрнең фәнни җитәкчесе була.

:: Рәмис Шәрәфович, мондый кәттә приборларның Казанда эшләнүен күпләр белмәгәндер дә дип уйлыйм...

– Совет хакимияте вакытында галәмгә безнең институтта җитештерелгән оптик-электрон приборлар куелган космик кораблар, ясалма иярченнәр бик күп җибәрелде. Әмма аларның күбесе «яшерен» грифы белән эшләнде. Шуңа күрә сез хаклы дип уйлыйм. Белеп, ишетеп бетермәгәннәрдер. Хәзер исә махсус комиссия карары белән «яшерен» грифы юкка чыгарылды.

:: Сөйләгез әле, бу приборлар ничек эшли дә ниләр күрсәтә? Беркөнне шулай күршем кергән иде. Йортын рәсмиләштереп йөргәндә, кулына галәмнән төшерелгән рәсем тоттырганнар. Капкасын ачып, ишегалдына кереп бара торган чагы эләккән. Безне гел шулай тикшереп торалармы икән әллә дип борчуга калган.

– Алай ук борчылырга кирәкми, әлбәттә. Бу сурәт документлаштыру өчен генә алынган. Безне беркем дә күзәтеп тормый. Приборлар исә түбәндәгечә эшли: җир өслегеннән чагыла торган нурларны башта электр сигналларына, аннан цифрлы кодка әйләндерәләр дә җиргә тапшыралар. Җир тирәли орбитадан кирәк кадәр мәйданны берьюлы сурәткә төшерергә, бер үк ноктага күп тапкыр кире кайтырга мөмкин. Приборлар гадәттә ике төргә бүленә. Беренчесе – нигездә хәрбиләр өчен. Иярченнәрдәге приборлар ярдәмендә оператив рәвештә корабльләрне, самолетларны, танклар һәм башка хәрби техниканы төшереп, «Сугыш хәрәкәтләре театры»н даими контрольдә тоталар. Икенчесе көнкүреш темасына кагыла. Мәсәлән, җир тетрәүне, су басуларны булдырмас өчен тикшеренүләр алып барыла. Галәмнән, әйтик, нефть һәм газ үткәргечләрнең тишелеп агып ятуы да бик яхшы күренә. Андый аварияләрнең кайчагында кеше еллар буена аяк басмаган урыннарда булуын исәпкә алсаң, приборларның файдасы әйтеп бетергесез. Күпме һәлакәттән коткара дигән сүз бит. Урмандагы янгыннар, су басулар белән дә шундый ук хәл. Электрон-оптик приборлар гади күзгә бертөрле булып күренгән җылы һәм салкын суны да бик җиңел аера. Диңгез һәм елгаларның индустриаль юынтык сулар белән ни дәрәҗәдә пычрануын да бик ачык күрсәтә. Җылы һәм салкын һава агымнарына карап, бер айга кадәр алдан метереологик фараз ясарга була. Хәтта дөнья буенча күпме иген уңышы алыначагын да белергә була. Төньяк Боз океанында йөзүче корабларга юл да күрсәтә ул. Безнең приборларның төгәллеге автомобильнең номерын танырга, су астыннан, хәтта җир астыннан күрергә, инфракызыл нурлар ярдәмендә төнлә дә яхшы сурәт алырга мөмкинлек бирә.

shutterstock.com/ru

:: Җиргә бу сигналлар төсле сурәт рәвешендә килеп җитте, ди. Алга таба аларны нинди язмыш көтә?

– Төшерден дә бетте түгел әле. Җирдә галәмнән төшерелгән сурәтләрне кабул итү, эшкәртү үзәкләре эшли. Теләсә нәрсәне төшерергә ярый дигән сүз түгел бит бу. Һәрберсенең үз таләпләре, шартлары бар. Кыскасы, һәр эш килештерелгән булырга тиеш. Приборлар да төрле. Бер үк булганнарының саны гадәттә дистәдән артмый, бер генә данә булган очраклар да бар. Аларның һәркайсы төрледән-төрле мәгълүмат җибәреп тора. Галимнәр шуларны эшкәртү белән мәшгуль дә инде. Бу җәһәттән СССРда Космик тикшеренүләр институты да беренчеләрдән булып эшли башлаган иде һәм бу өлкәдә безгә фәнни консультант, куратор булды. Аны озак еллар милләттәшебез, академик Роальд Сәгъдиев җитәкләде.

:: Таләпләр төрле булгач, димәк, приборлар заказ буенча эшләнә дип уйларга нигез бар?

– Әйе. Мәсәлән, Оборона министрлыгы заказ бирә, үз таләпләрен куя. Приборларны башта җирдә сынап карыйлар. Галәмгә җибәрелгәч тә, алынган сурәтләрне дә кат-кат тикшерәләр. Чөнки җирнең кайсы өлеше күрсәтелгәнен төгәл билгеләргә кирәк. Ялгышмас өчен, самолеттан да шул ук урыннарны төшерәләр. Туры киләме икәнлеген чагыштырып карыйлар. Масштаблар бик зур бит, ялгышырга ярамый.

:: Бу юнәлеш буенча үрнәк алыр илләр бар идеме?

– Америка белән читтән торып кына ниндидер элемтәләр бар иде дип әйтергә ярыйдыр. Без тигез дәрәҗәдә эшләп бардык. Шуңа күрә җитештергән приборларыбыз да бертөрлерәк һәм бер вакыттарак булды. Бер-беребездән алга да китмәдек, артка да калмадык. Әмма ачыктан-ачык аралашып яшәмәдек. Халыкара симпозиумнарда гына очрашып, фикер алыша идек. Көндәшлек дигән нәрсә бик көчле иде ул вакытта.

:: Белгәнебезчә, космик программалар бик нык кыскарган вакытлар да булды. Сезгә бу хәлләр ничегрәк тәэсир итте?

– Булды андый хәлләр. Әмма без югалып калмадык. Таралып китмәс өчен барысын да эшләргә тырыштык. Үз аппаратларыбызны, мәсәлән, АН-38, Ту-154 самолетларына, Ми-8 вертолетына җайлаштырып үзгәрттек. Нәтиҗәләр зарланырлык булмады. «Җиргә төшәргә» дә туры килде. Икътисад өчен авыр 1990–2002 елларда конверсия программасы кысасында республиканың «Татавтодор» берләшмәсе белән килешү нигезендә фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструктор эшләре үткәрелде. Бу өлкәдә уңышлы гына эшләп, берничә төрле прибор чыгарылды һәм производствога кертелде. Шулай ук шикәр заводлары, эчемлек фабрикаларына зур төгәллек белән шикәр микъдарын күрсәтә торган прибор тәкъдим иттек. Электр станцияләре өчен турбина подшипникларының температурасын даими күрсәтә торган прибор да җитештердек.

:: 2002 елда яңадан дәүләт гамәли-оптика институтына күчкәч, сезнең җитәкчелектә шактый катлаулы эш – самолет һәм вертолетларны һөҗүм итүче ракеталардан саклау системалары проектлана һәм эшләнә...

– Бу өлкәдә дә без пионерлар булдык. Аңлашылганча, самолет, вертолетларны шартлату өчен җибәрелгән ракеталар мотор җылысына килә. Эләктеңме, беттең дигән сүз инде. Ә безнең приборлар исә бу ракеталарның төбәү системасындагы датчикларны лазер нуры ярдәмендә юкка чыгара, ягъни яндыра һәм ракета читкә китәргә мәҗбүр була. Бүген, аңлыйсыздыр, мондый приборлар җитештерү бигрәк тә актуаль.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Спорт


ak-bars.ru

Бишенче финал

«Ак барс»та дүртенче мәртәбә Гагарин Кубогын яулау турында хыялланалар. Моның өчен нибары дүрт адым ясыйсы калды. Моңа кадәр безнекеләр 4 мәртәбә финалга чыгып, шуның өчесен җиңү белән тәмамлаган иде. Ә быелгы көндәш әлегә билгесез: СКА белән ЦСКА Көнбатышта кемнең көчлерәк икәнен ачыклаган арада, «Ак барс» бераз хәл җыячак.

«Мин инде аны күптән оныттым». 2019 елның 3 мартында «Авангард»ка оттырып, плэй-оффның беренче өлешендә үк ярыштан төшеп калуы, аннары эшеннән китүен искә төшергәч, «Ак барс»ның баш тренеры Зиннәтулла Билалетдинов әнә шулай дип җавап бирде. «Хәтта кичә ни булганын да хәтерләмим», – диде ул журналист кавеме ике көннең берендә шул хакта сорагач. Элегрәк мондый кабатлауларга ачуы чыгар иде. Быел исә еш елмая остаз. Хәтта уңышсыз тәмамланган уеннардан соң да.

Аның каравы хоккейчылар да, тамашачы да онытмады 2019, 2021 һәм 2022 елларда рәттән өч җиңелүне. 2019да безнекеләр Гагарин Кубогының гамәлдәге иясе иде. Шуңа күрә плэй-оффның беренче өлешендә үк һәм, җитмәсә, 0:4 исәбе белән оттыруны авыр кабул иттеләр. Шуннан соң Зиннәтулла Билалетдинов вазыйфасыннан баш тартырга мәҗбүр булды. Аны лаеклы ялга озаттылар дип уйладык. Мәскәү белән Нижгар арасында үскән милләттәшебез урынына яшь Дмитрий Квартальновны чакырдылар. Яңа тренерның беренче сезоны коронавирус баш калкыткан чорга туры килде, шуңа күрә плэй-оффны тәмамлый алмадылар. Аннары исә, гөнаһ шомлыгына, ике ел рәттән янә «Авангард» туры килде. 2021дә Көнчыгыш финалындагы каршылык 7 матчка сузылды һәм ахыры ул вакытта Балашихада чыгыш ясаган команданың өстенлеге белән тәмамланды. Узган ел исә көндәшләр плэй-оффның беренче өлешендә үк очрашты һәм янә «Авангард» көчлерәк булып чыкты. Ничек онытмак кирәк моны?

Быел менә янә «Авангард» белән очрашырга туры килде. Билалетдинов әйләнеп кайтмаса, очрашырлар иде микән? Хәер, кем әйтмешли, тарих шарт фигыльне кабул итми. Зиннәтулла Хәйдәр улы янә «Ак барс»та һәм Казан командасы янә Гагарин Кубогы өчен көрәшә. Кайчак хәтта соңгы берничә елдагы җиңелүләр гомумән булмаган, ә баш тренер беркая да китмәгән кебек тоела. Ләкин бу читтән караганда гына шулай. Җиңү тәмен оныткан командага финалга барып җитү җиңел булмады. Биш матчның бишесе дә нибары 1 алкалык аерма белән тәмамланды. Өч мәртәбә овертаймга чыгарга туры килде. Замансында «Ак барс» белән Гагарин Кубогын откан, хәзер исә «Авангард»та эшләүче Александр Свитов трибунага барып төшкән алка өчен тамашачы белән әйткәләшә икән, бозда ни булганын күз алдына китерегез инде.

Билалетдиновка иң катлаулысы башка остаз теләге белән тупланган һәм тугызынчы урынга ук тәгәрәгән команданы үз көенә уйнату булды. Үзе яшерми бит: башта «Нефтехимик», аннары «Адмирал»га каршы узган очрашулар Казан командасы өчен зур сабак булды. Билалетдинов дәресләре беркайчан да туктамый. Әнә бит плэй-оффта «файдасыз уенчы» булып танылган Вадим Шипачев «Авангард»ка каршы узган очрашуларда җиңү китергән ике алка кертә һәм сакчыларга ярдәм итү өчен бар көченә артка чаба. Билалетдинов дәресләренең эчтәлеген бөтен хоккей дөньясы белә: тырышып эшләргә кирәк! Тапталган һәм күптән билгеле сүзләр булса да, Зиннәтулла Билалетдинов алар ярдәмендә дүртенче җиңүенә таба атлый. 0:2 исәбе белән җиңелеп барган ике очрашуның язмышын үз файдасына хәл итүнең сере әнә шунда. «Мин Тарасов та, башка кеше дә түгел. Мин – Билалетдинов. Нәрсә уйласам, һәрвакыт чын күңелдән шуны сөйлим. Егетләр ишетергә теләгән сүзләрне әйтергә оялмыйм. Чөнки алар моңа лаек. Берсенең дә койрыгын борганым юк, әмма нәрсәне ничек эшли аласыларын яхшы беләм», – ди остаз.

Шулай итеп, Билалетдинов бишенче финалына чыкты. Алдагы дүртнең өчесендә җиңү яулый алды. Бары берсен – 2015 елда СКАга каршы узганы гына аның өчен җиңелү белән тәмамланды. 2018 елда булган соңгы финалда исә «Ак барс» ЦСКАдан өстен чыкты. Быелгы хәлиткеч очрашуларда безнекеләргә әнә шул ике команданың берсе белән очрашырга туры киләчәк. «Икесе дә көчле составка ия. Кем туры килә, шуңа каршы уйнаячакбыз. Без әзерләнәбез», – диде Зиннәтулла Билалетдинов. Икесе өчен дә аерым планы булганына беркем шикләнми. Ял иткәндә чал чәчле тренер хоккей карамаган дип уйлыйсызмы әллә? Финал очрашулары 17 апрельдә башлана.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе

САБИРОВА Фәния Габидулла кызы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе хокук саклау органнары белән берлектә эшләү секторы мөдире Сабиров Марат Тәлгат улының авыр кайгысын уртаклаша.

ҮСМЕРГӘ «ӨСТӘН» КАРАРГА ЯРАМЫЙ

«TAMGA» лабораториясе

«Үзебезгә килгән яшьләргә «бездә сине кызыксындырырлык темалар күтәрелә» дип әйтә алабыз». Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында «TAMGA» режиссерлар лабораториясе узды. Киң җәмәгатьчелектә каршылыклы фикерләр уяткан әлеге лаборатория бу юлы нәрсәсе белән шаккатырды? Үсмерләр өчен тәгаенләнгән театр нинди хата-ялгышлардан сакланырга тиеш? Без әнә шуны белештек.

«Татар-информ» / Владимир Васильев

Яшьләр театры һәрчак заман ритмнарын тоеп эшли. «TAMGA» лабораториясе дә – театрның үз алдына куйган сынавы, яңа темаларга һәм жанрларга, иҗади тандемнарга чыгу ысулы. Традиция буенча, лабораториядә иҗади портфолиосында балалар һәм яшүсмерләр өчен спектакльләр булган яшь режиссерлар (Олег Молитвин, Лидия Хазова һәм Степан Пектеев) катнашты. Быелгы «TAMGA»ның темасы – фантастика. Чакырылган режиссерлар Шамил Идиятуллин, Кир Булычев һәм Адлер Тимергалин иҗатына мөрәҗәгать итте. Биш көн дәвамында балалар һәм яшүсмерләр өчен эскизлар әзерләп, соңгы көнне алар әзер эшләрен тамашачыларга һәм театр тәнкыйтьчеләренә тәкъдим итте.

Театрның баш режиссеры Ренат Әюпов фикеренчә, фантастика белән бары тик кино җитештерү өлкәсе шөгыльләнә ала, театрда аны эшләп булмый.

– Өч эскизда да видео, киноэкран белән эшләделәр. Фантастика – кино өчен кирәкле әйбер, театрда аның белән шөгыльләнеп булмый. Без кеше психологиясе, аның күңелендә, мохитендә ниләр булганын, дөньяга үзгәреше турында сөйлибез. Космик цивилизацияләрнең бер-берсе белән бәрелешүе – проза һәм кино өчен әйбәт. Театр кеше тарихы белән шөгыльләнергә тиеш, – ди режиссер. – Эскизларны әзерләгән режиссерлар үзләре дә сизмәстән кино алымнары белән шөгыльләнеп, артистларны оныттылар. Автор да читтәрәк калды. Әйтик, Адлер Тимергалинның прозасы бик әйбәт, ләкин анда Голливуд киноларыннан алынган мохитне артистлар аркылы уздырып, гомуми фантастика килеп чыккан. Кеше тарихын, бу очракта балаларның, яшьләрнең Жир шарын, үз телен, йортын, әти-әнисен югалтуның драмасын җиткерә алмадылар. Тышкы эффектка – музыка, кием, пластикага бирелеп, авторны онытты режиссер.

«Үзебезгә килгән яшьләргә «кара, бездә дә бик кызык нәрсәләр бар» дип әйтә алабыз». Кариев театры директоры Луиза Шарова иҗади лаборатория турында шулай диде.

– Лаборатория темаларын без ел саен үзгәртеп торабыз. Быел фантастикага мөрәҗәгать итәргә булдык. Үзенчәлеге – без балалар һәм яшүсмерләр өчен һәр заманда да актуаль, кызыклы булган жанрны сайладык. Аннан да бигрәк, үзебезнең авторларга һәм совет чоры фантастикасының үрнәкләренә мөрәҗәгать иттек. Яшь тамашачы театры чит ил сериаллары белән берничек тә ярыша алмый, билгеле, әмма без үзебезгә килгән яшьләргә «кара, бездә дә бик кызык нәрсәләр бар» дия алабыз, – ди театр директоры. – Лаборатория ул – театрның чит режиссерларны чакырып, әсәрләрне сайлап, үзенә күрә тест ясавы: барып чыгамы, юкмы? Режиссерның актерлар, материал белән ничек эшләвен күрәсең шул 5 көн эчендә, аның алымнарын, зәвыгын, эстетикасын… Актерлар шушы экстремаль шартларда чыныгалар, тәҗрибә туплыйлар, яңа алымнарга өйрәнәләр. Ә инде эскизны тәкъдим иткәннән соң, без, театрның җитәкчелеге һәм иҗат командасы, карыйбыз һәм сайлыйбыз: нәрсә алга таба сәхнә өчен яраклы һәм кирәкле була ала. Бу лабораториядә күңелгә хуш килгән эшләр булды.

Әгәр син нәрсәдер эшләргә алынасың, эзләнәсең, максатлар куясың, алга барасың икән (бигрәк тә моңарчы кеше әллә ни йөреп карамаган сукмак булса), һичшиксез абынырга да, егылырга да мөмкинсең. Ансыз булмый. Бала тәпи атлап киткәндә, ничә егыла…

Луиза Шарова сүзләренчә, лаборатория форматы – ул табигый һәм театр өчен әсәрләрне, режиссерларны сынап карый торган киң таралган формат.

– Бездә нигәдер бу сүз зур курку һәм шикләнү уята. Ниндидер яман нәрсәләр эшләнеп ятмыймы ул лабораториядә, янәсе… Юк, гап-гади эш механизмы ул. Ә ялгышлар-хаталар теләсә кайсы режиссерда, иҗат командасында булырга мөмкин. Кайчакта бик яхшы команда тупланса да. Сайлаган материал белән эш барып чыкмаган очраклар да була… Спектакль тудыру – иҗади процесс… Яшьләр театрының төп хатасы, ялгышы, хәтта җинаяте дә – яшьләрне үзеннән читләштерү, этәреп җибәрү. Яки аларга югарыдан торып акыл өйрәтү: болай булыгыз, ә болай булырга ярамый, дип. Менә шул мизгелдә без аларның игътибарын гына түгел, ә ихтирамын да мәңгегә югалтабыз. Безнең яшь тамашачылар «сез безнең белән бер тигезлектә сөйләшәсез» дигәндә, безгә канатлар үсә, – диде директор.

Ренат Әюпов фикеренчә, лаборатория беренче чиратта яшь актерларның үсеше өчен кирәк.

– Үзебезнең мохиттә генә яшәү барыбер туйдыра. Лаборатория театрның, артистларның профессиональ дәрәҗәсен үстерер өчен биш ел элек уйлап табылды. Кайвакыт «TAMGA» лабораториясендәге эскизлар мөстәкыйль спектакльгә дә әверелә. Әйтик, шуларның берсе – «Камыр батыр». Әмма бер куркыныч ягы да бар: кайвакыт эскизны аерым спектакль итеп эшләгәндә, анда табылган мохит һәм идея тар-мар килә. Аның бөтен мөмкинлеге юкка чыга, ул тартыла, нәтиҗәдә чәчелеп бетә. Кызганыч, «Камыр батыр»да шулай булды. Кечкенә генә ташны айсбергка әйләндереп утыруның мәгънәсе юк. Ул кечкенә генә таш булып калсын, ләкин үзенең мәгънәви фәлсәфәсен алып барсын. Эскиз үзенең эшен башкаргач, шул җитә дип саныйм мин.

«Без үзебезнең татар мохитендә генә чикләнеп яши алмыйбыз». Ренат Әюпов фикеренчә, татар сәхнәсендә рус, чуаш, мари һәм башка әсәрләр дә булырга тиеш.

– Монысы да артистларның профессиональ үсешенә кирәк. Без бит татар телендә уйныйбыз бу әсәрләрне. Заманча прозалар да бик кирәк. Ләкин алар бик аз. Театр бөтен драматургияне үтәргә тиеш. Шул вакытта гына ул яшь тамашачыларны кызыксындыра ала. Әмма агрессив күренешләр, тарихлар яшь тамашачылар театры өчен кирәкми. Агрессиядән сакланырга кирәк. Без бу әйбергә юл куймыйбыз да. Кайсыдыр кечкенә генә эпизодларда килеп чыга, ләкин ул концепциягә бәйле. Психикасы ныгып бетмәгән чорда балага олы кешенең фикерен тагарга ярамый. Төрле караш, «менә болай да була» дигән ирекне дә бирергә ярамый. Әйтик, традицион булмаган мөнәсәбәтләр. Театр мондый әйбергә якын да барырга тиеш түгел. Дөньяда табигый кыйммәтләр бар: гаилә, кешелеклелек, кеше язмышы… Боларны без һәрвакыт пропагандаларга тиеш.

Ләйсән САФИНА

АШ-СУ ОСТАСЫ ИЛДАР НИГЪМӘТҖАНОВ:

«Ризык әзерләгәндә, ир-атларның фантазияләре яхшырак эшли»

Әтнә районының Күшәр авылында гомер кичерүче Илдар Нигъмәтҗанов бу сүзләрен белми әйтми торгандыр. Үзе дә – 15 елдан артык аш-су өлкәсендә эшли торган ир-ат ул. Шәһәр ыгы-зыгысыннан туеп, Казанның бер затлы ресторанындагы эшен ташлап, туган ягына кайтып төпләнә дә…

…Әтнәдә өлкән повар булып эшли башлый. Аш-су юнәлешендә укып алган белемнәрен авыр да, җаваплы да эшендә файдалана башлый.

– Хәзерге яшьләргә җиңел эш кирәк. Безнең якларда аш-су остасына укучы егетләр бик күп үзе. Әмма укып бетерәләр дә башка өлкәдә эшли башлыйлар. Ризык әзерләү – чыннан да, шактый авыр эш бит ул. Көн буе аяк өстендә булырга кирәк, – ди Илдар Нигъмәтҗанов.

Моннан берничә ел элек 37 яшьлек әңгәмәдәшебезнең аякларына шактый катлаулы операция ясыйлар. Авыр әйбер күтәрүне тыеп, утырып кына эшли торган эш табарга киңәш итә табиблар. Тормыш иптәшенә – ныклы терәк, ике улларына яхшы әти булу теләге Илдар әфәндегә тик ятарга ирек бирми. Башта мәҗлес узасы йортларга барып, табын кора, аннан өйдә заказга ризыклар пешерә башлый.

– Шөкер, заказларым бик күп. Якын-тирәдәгеләр килеп ала, кайбер очракларда үзем илтеп бирәм. Хәзер бит авылда да төрледән-төрле тәм-томнар пешереп ятарга бөтен мөмкинлекләр бар. Район үзәгендә кибетләрнең ниндие генә юк, шактый әйберне шулардан алабыз. Булмаганын атна саен Казан яисә Арчага барып алып кайтабыз. Кыскасы, теләк кенә булсын, җае чыга, – ди аш-су остасы.

Кеше нәрсә сорый, шуны пешерәм, ди ул. Әзерләгән ризыкларын социаль челтәрләренә дә куеп бара. Андагы төрлелектән күзләр камаша.

– Барлык әйберләрне дә күңелемне биреп, яратып әзерлим. Шулай булганда, гади генә ризыклар да телеңне йотарлык була. Бигрәк тә торт пешерү, аны бизәү процессы ошый. Кабымлыклар, төрледән-төрле салатлар, чәкчәк, урама һәм башка камыр ризыклары, зефирдан чәчәкләр – барысын да әзерлим. Моңа кадәр пешереп карамаган ризыкны сорасалар да, кире бормыйм. Өйрәнәм дә пешерәм.

Илдар Нигъмәтҗановның шәхси архивыннан

Ярымфабрикатлар сораучылар да күп икән. Әңгәмәдәшебез аларын да әзерләп сата.

– Хәзер кешенең башы эштән чыкмый диярлек. Шуңа да ярымфабрикатларны күпләп алалар. Җайлы бит! Өйдә студент булган очракта, аңа биреп җибәрер өчен алучылар да күп, – ди ул.

Аш-су осталарының күпчелеге хатын-кыз затыннан булган заманда яшәгәч, ир-ат пешекчеләр белән аралашу – гайре табигый хәл. Ләкин әңгәмәдәшебез һөнәрне җенескә карап бүлү яклы түгел.

– Әни мине кечкенәдән хатын-кыз һәм ир-ат эшен аермаска өйрәтте. Канга сеңгән ул. Әтисез калгач, «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» мәкаленең мәгънәсенә дә төшендем. Шуңа да ир-ат пешекчеләргә сәерсенеп караучыларны аңламыйм. Тарихка күз салсаң да, иң данлыклы аш-су осталары арасында ир-атлар күп. Билгеле, хатын-кызлар бик тәмле пешерә, әмма ризык әзерләгәндә, ир-атларның фантазиясе яхшырак эшли, – ди Илдар Нигъмәтҗанов.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КАРА ҖИМЕШЛЕ ТОРТ РЕЦЕПТЫ

Җәемнәр өчен: 1 банка куертылган сөт (сгущенка), ике йомырка, 3 аш кашыгы (90 г тирәсе) какао порошогы, 150–200 г он, серкә белән сүндерелгән сода.
Барысын бергә салып, яхшылап күпертәбез. Әзер камырны дүрт өлешкә бүлеп җәябез, 15–20 минутка 180 градуска кадәр җылытылган духовкага озатабыз.
Крем өчен: 200 г кара җимеш (иттарткыч аша чыгарып), 500 г каймак, 200 г шикәр комы.
Барысын бергә болгатып, һәр җәем арасына сылыйбыз. Өстәге җәемгә әстерхан чикләвеге сибеп җибәрәбез.
Глазурь өчен: 100 г шоколад, 150 г сөт өсте (сливки).
Шоколадны эретеп, сөт өсте белән яхшылап болгатабыз да торт өстенә сибәбез.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 251

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+